**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

29.12.2015 1127-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының региональ дәүләт экология күзәтчелегенә тиешле хуҗалык һәм башка төрле эшчәнлек объектларында калдыклар белән эш итү өлкәсендә региональ дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру, шулай ук җитештерү һәм куллану калдыкларын урнаштырган өчен түләүне контрольдә тоту буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентын раслау турында» 09.12.2013, № 724-п боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының норматив-хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының региональ дәүләт экология күзәтчелегенә тиешле хуҗалык һәм башка төрле эшчәнлек объектларында калдыклар белән эш итү өлкәсендә региональ дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру, шулай ук җитештерү һәм куллану калдыкларын урнаштырган өчен түләүне контрольдә тоту буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентын раслау турында» 09.12.2013, № 724-п боерыгына (алга таба - Административ регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

аталышын түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының региональ дәүләт экология күзәтчелегенә тиешле хуҗалык һәм башка төрле эшчәнлек объектларында калдыклар белән эш итү өлкәсендә дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентын раслау турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының региональ дәүләт экология күзәтчелегенә тиешле хуҗалык һәм башка төрле эшчәнлек объектларында калдыклар белән эш итү өлкәсендә дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентын (алга таба – Административ регламент) расларга.».

2. Аталган боерык белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының региональ дәүләт экология күзәтчелегенә тиешле хуҗалык һәм башка төрле эшчәнлек объектларында калдыклар белән эш итү өлкәсендә региональ дәүләт күзәтчелеген башкару, шулай ук җитештерү һәм куллану калдыкларын урнаштырган өчен түләүне контрольдә тоту буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

аталышын түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының региональ дәүләт экология күзәтчелегенә тиешле хуҗалык һәм башка төрле эшчәнлек объектларында калдыклар белән эш итү өлкәсендә дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламенты”;

1.1 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

“Әлеге Административ регламент (алга таба - Регламент) юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә карата “региональ дәүләт экология күзәтчелегенә тиешле хуҗалык һәм башка төрле эшчәнлек объектларында калдыклар белән эш итү өлкәсендә дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру» дәүләт функциясен (алга таба - дәүләт функциясе, калдыклар белән эш итү өлкәсендә региональ дәүләт күзәтчелеге, дәүләт күзәтчелеге) үтәгәндә Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының (алга таба - ТР ЭТРМ) гамәл кылу вакытын һәм тәртибен билгели.

Калдыклар белән эш итү өлкәсендә региональ дәүләт күзәтчелеген үткәрү тәртибе Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 09.12.2013 № 721-п боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының региональ дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентында (алга таба – Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының региональ дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламенты) билгеләнгән региональ дәүләт экология күзәтчелегенең бер өлеше булып тора.»;

1.2 пунктында:

өченче абзацтагы “ТР ЭТРМ министры (алга таба - министр), ТР ЭТРМ министры урынбасары (алга таба – министр урынбасары) әмернамәсе белән” сүзләрен “Татарстан Республикасының экология һәм табигый ресурслар министры (алга таба – министр), Татарстан Республикасының экология һәм табигый ресурслар министры урынбасары (алга таба - министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе) белән» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта “эксперт оешмалары тарафыннан” сүзләреннән алда “Россия Федерациясенең илкүләм аккредитацияләү системасында аккредитацияләү турында законнары нигезендә аккредитацияләнгән (алга таба – эксперт оешмалары)” сүзләрен өстәргә;

1.3 пунктын түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

“1.3. Дәүләт функциясе түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясе Конституциясе (Российская газета, 1993, 25 декабрь, № 237, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексы, 30 декабрь, 2001 ел, № 195-ФЗ (алга таба – РФ КоАП) (Россия Федерациясенең Законнар җыентыгы, 2002, № 1, 1 ст.), кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясенең Җир кодексы, 25 октябрь, 2001ел, № 136-ФЗ (Россия Федерациясенең Законнар җыентыгы, 2001, № 44, 4147 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясенең Су кодексы, 3 июнь, 2006 ел, № 74-ФЗ (Россия Федерациясенең Законнар җыентыгы, 2006, № 23, 2381 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

1998 елның 24 июнендәге “Җитештерү һәм куллану калдыклары турында” № 89-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясенең Законнар җыентыгы, 1998, № 26, 3009 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2002 елның 10 гыйнварындагы “Әйләнә-тирә мохитне саклау турында” №7-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясенең Законнар җыентыгы, 2002, № 2, 133 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2008 елның 26 декабрендәге “Дәүләт контрольлеген (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольлекне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында” № 294-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 294-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясенең Законнар җыентыгы, 2008, № 52, 6249 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2006 елның 2 маендагы “Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында” № 59-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясенең Законнар җыентыгы, 2006, № 19, 2060 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2011 елның 4 маендагы “Аерым эшчәнлек төрләрен лицензияләү турында” № 99-ФЗ Федераль закон (Российская газета, 2011, 6 май, № 97, Россия Федерациясенең Законнар җыентыгы, 2011, № 19, 2716 ст., Парламентская газета, 2011, 13 май, № 23, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2003 елның 17 июлендәге “Калдыкларны чик аша күчерү турында” № 442 карары (Россия Федерациясенең Законнар җыентыгы, 2003, № 29, 3012 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 16 июлендәге “Аерым эшмәкәрлек эшчәнлеге төрләре башлануын хәбәр итү тәртибе турында” № 584 карары (Россия Федерациясенең Законнар җыентыгы, 2009, № 30, 3823 ст., үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 6 октябрендәге “Лицензиянең үрнәк рәвешен раслау турында” № 826 карары (Российская газета, 2011, 19 октябрь, № 234, Россия Федерациясенең Законнар җыентыгы, 2011, № 42, 5924 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 16 августындагы “I-IV куркыныч классындагы калдыкларны паспортлаштыру тәртибе турында” № 712 карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең № 712 карары) (Россия Федерациясенең Законнар җыентыгы, 2013, № 34, 4443 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 8 маендагы “Федераль дәүләт экология күзәтчелеге турында” № 426 карары (Россия Федерациясенең Законнар җыентыгы, 2014, № 20, 2535 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 3 октябрендәге “I-IV куркыныч классындагы калдыкларны җыю, транспортлаштыру, утильләштерү, йогышсызландыру, урнаштыру буенча эшчәнлекне лицензияләү турында” № 1062 карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 03.10.2015, № 1062 карары) (Россия Федерациясенең Законнар җыентыгы, 2015, № 41, 5670 ст.);

Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең 2007 елның 10 декабрендәге “Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең куркыныч калдыкларны җыю, транспортлаштыру, утильләштерү, йогышсызландыру, урнаштыру буенча эшчәнлекне лицензияләү буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентын раслау турында” № 848 боерыгы (алга таба – 10.12.2007, № 848 Ростехнадзор боерыгы) (Федераль башкарма хакимият органнарының норматив актлар бюллетене, 2008, № 15);

Россия Федерациясе Икътисади үсеш министрлыгының 2009 елның 30 апрелендәге “Дәүләт контрольлеген (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольлекне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында” Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру хакында” № 141 боерыгы (Российская газета, 2009, 14 май, № 85, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Техник җайга салу һәм метрология буенча федераль агентлыкның 2009 елның 15 декабрендәге “Илкүләм стандарт раслау турында” № 1091-ст боерыгы (алга таба – № 1901-ст боерык) (текст рәсми рәвештә басылып чыкмаган);

Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең 2010 елның 24 декабрендәге “I-IV куркыныч классындагы калдыкларны паспортлаштыруны оештыру турында” № 441 боерыгы (алга таба – Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең № 441 боерыгы) (текст рәсми рәвештә басылып чыкмаган, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең 2011 елның 28 гыйнварындагы “Росприроднадзор тарафыннан җитештерү һәм куллану калдыкларына федераль статистик күзәтүне оештыру өчен статистик инструментарий раслау турында” № 17 боерыгы (Вопросы статистики, 2011, № 5, рәвешләрен теркәмичә бастырып чыгарылган);

Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең 2014 елның 18 июнендәге “Калдыкларның федераль классификация каталогын раслау

турында” № 445 боерыгы (алга таба – № 445 Росприродназдор боерыгы) (Российская газета, 2014, 19 сентябрь, № 214, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Табигый ресурслар министрлыгының 2001 елның 15 июнендәге “Куркыныч калдыкларны әйләнә-тирә табигый мохит өчен куркыныч классына кертү критерийларын раслау турында” № 511 боерыгы (алга таба – № 511 Россия Табигать министрлыгы боерыгы) (Природно - ресурсные ведомости, 2001, № 45);

Россия Федерациясе Табигый ресурслар министрлыгының 2010 елның 25 февралендәге “Калдыклар барлыкка килү нормативларын һәм аларны урнаштыруга лимитлар эшләү һәм раслау тәртибе турында” № 50 боерыгы (алга таба – РФ Табигать министрлыгының 25.02.2010 № 50 боерыгы) (Федераль башкарма хакимият органнарының норматив актлар бюллетене, 2010, № 17, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Табигый ресурслар министрлыгының 2011 елның 1 сентябрендәге “Калдыклар белән эш итү өлкәсендә исәпкә алу тәртибен раслау турында” № 721 боерыгы (алга таба – РФ Табигать министрлыгының 01.09.2011 № 721 боерыгы) (Федераль башкарма хакимият органнарының норматив актлар бюллетене, 2011, № 44, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Табигый ресурслар министрлыгының 2011 елның 8 сентябрендәге “Татарстан Республикасы территориясендә хуҗалык һәм башка төрле эшчәнлек башкарганда әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаучы һәм федераль дәүләт экология күзәтчелегенә тиешле объектлар исемлеген раслау турында” № 727 боерыгы (Государственное управление ресурсами, 2013, махсус басма, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Табигый ресурслар министрлыгының 2011 елның 30 сентябрендәге “Калдыкларның дәүләт кадастрын алып бару тәртибен раслау турында” № 792 боерыгы (Федераль башкарма хакимият органнарының норматив актлар бюллетене, 2011, № 50);

Россия Федерациясе Табигый ресурслар министрлыгының 2014 елның 5 августындагы “Калдыклар барлыкка килү нормативларының һәм аларны урнаштыру лимитларының проектларын эшләү буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында” № 349 боерыгы (алга таба – Россия Табигать министрлыгының № 349 боерыгы) (Российская газета, 2015, 30 гыйнвар, № 18/1, махсус басма);

Россия Федерациясенең Баш дәүләт санитар табибының 2001 елның 13 июнендәге “Санитар кагыйдәләр – СП 1.1.1058-01 гамәлгә кертү турында” № 18 карары (алга таба – СП 1.1.1058-01) (Федераль башкарма хакимият органнарының норматив актлар бюллетене, 2001, № 45, Российская газета, 2001, 13 ноябрь, № 222, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясенең Баш дәүләт санитар табибының 2003 елның 30 апрелендәге “Санитар-эпидемиологик кагыйдәләрне һәм СанПиН 2.1.7.1322-03 нормативларын гамәлгә кертү турында” № 80 карары (алга таба – СанПиН 2.1.7.1322-03 “Җитештерү һәм куллану калдыкларын урнаштыруга һәм зарарсызландыруга карата гигиена таләпләре” (Российская газета, 2003, 28 май, № 100);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 06 июлендәге “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы мәсьәләләре” № 325 карары (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив-хокукый актлары җыентыгы” журналы, 2005, № 28, 0654 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 21 сентябрендәге “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының һәм Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының региональ дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазифаи затлары исемлеген раслау турында” № 784 карары (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив-хокукый актлары җыентыгы” журналы, 2011, № 40, 2038 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 2013 елның 09 декабрендәге “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының региональ дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентын раслау турында” № 721-п боерыгы (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив-хокукый актлары җыентыгы”, 2014, № 33-34, 1040 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).”;

1.5.1 пунктының 2 пунктчасында “министр (министр урынбасары) әмернамәсе” сүзләрен “министр (министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе)” сүзләренә алмаштырырга;

1.5.2 пунктында:

3 пунктчадагы “министр (министр урынбасары) әмернамәсе” сүзләрен “министр (министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе)” сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктчадагы “министр (министр урынбасары) әмернамәсе” сүзләрен “министр (министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе)” сүзләренә алмаштырырга;

13 пунктчада “тикшерүләрне исәпкә алу дәфтәрендә” сүзләреннән соң “(булган очракта) сүзләрен өстәргә;

1.5.3 пунктында түбәндәге эчтәлекле 8, 9 пунктчаларын өстәргә:

“8) СССР һәм РСФСР башкарма хакимияте органнарының норматив-хокукый актларында билгеләнгән һәм Россия Федерациясе законнарына туры килми торган таләпләрнең үтәлешен тикшерергә;

9) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылмаган муниципаль-хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрнең һәм таләпләрнең үтәлешен тикшерергә”.;

1.6.1 пунктында:

3 пунктчаны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

“3) тикшерү нәтиҗәләре белән танышырга һәм тикшерү актында үзенең тикшерү нәтиҗәләре белән танышуы, алар белән, шулай ук ТР ЭТРМ вазифаи затларының аерым гамәлләре белән килешүе яки килешмәве турында күрсәтергә.

Тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр белән, яисә ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмә белән ризалашмаган очракта, тикшерү актын алган көннән соң унбиш көн дәвамында язма рәвештә тикшерү актына карата һәм (яки) ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмәгә карата тулаем алганда яки аның аерым нигезләмәләренә карата ТР ЭТРМ ризасызлыклар тапшырырга хокуклы. Шул ук вакытта юридик зат, шәхси эшмәкәр мондый ризасызлыкларга мондый ризасызлыкларның нигезле булуын дәлилли торган документларны яки аларның таныкланган күчермәләрен теркәргә яисә килештерелгән вакытка аларны дәүләт контрольлеге (күзәтчелеге), муниципаль контрольлек органына тапшырырга хокуклы. Аталган документлар тикшерелә торган затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документлар (электрон документлар җыелмасы) рәвешендә җибәрелергә мөмкин.

Түбәндәге эчтәлекле 5 пунктчасын өстәргә:

“5) Россия Федерациясе карамагындагы эшмәкәрләрнең хокукларын яклау буенча Вәкаләтле Вәкилне яисә Татарстан Республикасы Президенты карамагындагы эшмәкәрләрнең хокукларын яклау буенча Вәкаләтле Вәкилне тикшерүдә катнашырга җәлеп итәргә”.;

1.7 пунктының алтынчы абзацында “тикшерүләрне исәпкә алу дәфтәрендә” сүзләреннән соң “(булган очракта) сүзләрен өстәргә;

2.1.1 пунктында “Интернет” челтәрендә” сүзләрен “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – “Интернет” челтәре)” сүзләренә алмаштырырга;

2.1.5 пунктының беренче абзацында “Интернет-сайтында” сүзләрен “Интернет” челтәрендә” сүзләренә алмаштырырга;

2.3.1 пунктының өченче абзацында “кече предприятиеләргә карата” сүзләреннән соң “илле сәгатьтән дә артык түгел” сүзләрен өстәргә;

2.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 2.3.2 пунктчасын өстәргә:

“2.3.2. Планлы тикшерүләр өч елга бер тапкырдан да артык булмаган ешлыкта үткәрелә”.;

Административ регламентның 2.4.2 пунктындагы 3 пунктчада “басылып чыккан министр әмернамәсе” сүзләрен “басылып чыккан министр (министр урынбасары) әмернамәсе (боерыгы)” сүзләренә алмаштырырга;

2.5 пунктында:

икенче абзацны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының региональ дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазифаи затлары исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 21 сентябрендәге “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының һәм Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының региональ дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазифаи затлары исемлеген раслау турында” № 784 карары белән расланды;

2.2 таблицаны төшереп калдырырга;

3 таблицада:

1.2 пунктында:

“Мәҗбүри таләпнең тәгъбире” графасында “файдалану” сүзен “транспортлаштыру, эшкәртү, утильләштерү” сүзләренә алмаштырырга;

“Мәҗбүри таләпне билгели торган норматив-хокукый акт” графасында “Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 28.03.2012 № 255 карары белән расланган “I-IV куркыныч классындагы калдыкларны җыю, алардан файдалану, зарарсызландыру һәм урнаштыру буенча эшчәнлекне лицензияләү турында нигезләмә” сүзләрен “Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 03.10.2015 № 1062 карары белән расланган I-IV куркыныч классындагы калдыкларны җыю, транспортлаштыру, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру буенча эшчәнлекне лицензияләү турында нигезләмә” сүзләренә алмаштырырга;

“Тикшерү барышында юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тапшыра торган документлар исемлеге” графасында “файдалану” сүзен “транспортлаштыру, эшкәртү, утильләштерү” сүзләренә алмаштырырга;

1.3 пунктындагы “Мәҗбүри таләпне билгели торган норматив-хокукый акт” графасында “Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 28.03.2012 № 255 карары белән расланган “I-IV куркыныч классындагы калдыкларны җыю, алардан файдалану, зарарсызландыру һәм урнаштыру буенча эшчәнлекне лицензияләү турында нигезләмә” сүзләрен “Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 03.10.2015 № 1062 карары белән расланган I-IV куркыныч классындагы калдыкларны җыю, транспортлаштыру, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру буенча эшчәнлекне лицензияләү турында нигезләмә” сүзләренә алмаштырырга;

1.4 пунктындагы “Мәҗбүри таләпне билгели торган норматив-хокукый акт” графасында “Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең 19.10.2007 № 703 боерыгы белән расланган Калдыклар барлыкка килү нормативларының һәм аларны урнаштыру лимитларының проектларын эшләү буенча методик күрсәтмәләр” сүзләрен “Россия Табигать министрлыгының № 349 боерыгы белән расланган Калдыклар барлыкка килү нормативларының һәм аларны урнаштыру лимитларының проектларын эшләү буенча методик күрсәтмәләр” сүзләренә алмаштырырга;

1.10 пунктындагы “Мәҗбүри таләпне билгели торган норматив-хокукый акт” графасын түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

“Җитештерү һәм куллану калдыклары турында” 24.06.1998 № 89-ФЗ Федераль законның 1, 14 статьялары; № 1091-ст боерыгы белән расланган РФ ГОСТ Р 53691-2009 Илкүләм стандарты; РФ Хөкүмәтенең № 712 карары; № 445 Росприроднадзор боерыгы белән расланган Калдыкларның федераль классификация каталогы”;

1.11 пунктында “Мәҗбүри таләпне билгели торган норматив-хокукый акт” графасын түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

“РФ Хөкүмәтенең № 712 карары; Россия Табигать министрлыгының № 511 боерыгы белән расланган Куркыныч калдыкларны әйләнә-тирә табигый мохит өчен куркыныч классына кертү критерийлары; № 441 Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт боерыгы”;

4 таблицада:

16 пунктта “Тикшерү үткәрү өчен күрсәтелә торган документ” графасын түбәндәге редакциясендә бәян итәргә: “Куркыныч калдыкларны җыю, алардан файдалау, зарарсызландыру, урнаштыру эшчәнлегенә бирелгән лицензияләр реестрыннан өземтә”;

18 пункттагы “Документ рәвешен билгели торган норматив-хокукый акт” графасында “Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 28.03.2012 № 255 карары белән расланган I-IV куркыныч классындагы калдыкларны җыю, алардан файдалау, зарарсызландыру, урнаштыру эшчәнлеген лицензияләү турында нигезләмә” сүзләрен “Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 03.10.2015 № 1062 карары белән расланган I-IV куркыныч классындагы калдыкларны җыю, транспортлаштыру, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру буенча эшчәнлекне лицензияләү турында нигезләмә” сүзләренә алмаштырырга;

45-50 пунктларындагы “Документ рәвешен билгели торган норматив-хокукый акт” графасында “Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең 19.10.2007 № 703 боерыгы белән расланган Калдыклар барлыкка килү нормативларының һәм аларны урнаштыру лимитларының проектларын эшләү буенча методик күрсәтмәләр” сүзләрен “Россия Табигать министрлыгының № 349 боерыгы белән расланган Калдыклар барлыкка килү нормативларының һәм аларны урнаштыру лимитларының проектларын эшләү буенча методик күрсәтмәләр” сүзләренә алмаштырырга;

51 пункттагы “Документ рәвешен билгели торган норматив-хокукый акт” графасында “Россия Федерациясе Табигый ресурслар министрлыгының 2002 елның 2 декабрендәге “Куркыныч калдык паспортын раслау турында” № 785 боерыгы” сүзләрен “РФ Хөкүмәтенең № 712 карары” сүзләренә алмаштырырга;

“Тикшерү үткәрү өчен күрсәтелә торган документ” графасында 62-86 пунктларының нумерациясен тиешенчә 58-82 пунктлары итеп санарга;

Административ регламентның 5.1.1 пунктының дүртенче абзацында “министр (министр урынбасары) әмернамәсе” сүзләрен “министр (министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе)” сүзләренә алмаштырырга;

5.1.3 пунктында:

икенче абзацтагы “ТР ЭТРМ боерыгы (әмернамәсе)” сүзләрен “министр (министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе)” сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацтагы “әмернамәсе” сүзен “боерыгы (әмернамәсе)” сүзләренә алмаштырырга;

5.1.4 пунктында:

беренче абзацтагы “әмернамәсе” сүзен “министр (министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе)” сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацтагы “боерыгы (әмернамәсе)” сүзләрен “министр (министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе)” сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацтагы “әмернамәсе” сүзен “министр (министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе)” сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта “электрон документлар рәвешендә” сүзләреннән алда “көчәйтелгән квалификацияле электрон санлы имза белән имзаланган” сүзләрен өстәргә;

5.1.6 пунктындагы бишенче абзацта “әмернамәсе” сүзен “министр (министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе)” сүзләренә алмаштырырга;

5.1.7 пунктында:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

“Әгәр контрольлек буенча чаралар барышында контрольлек буенча чаралар үткәрү объекты булган хуҗалык яки башка төрле эшчәнлекнең законнардагы таләпләрнең бозылуына бәйле икәнлеге ачыкланса, мондый очракларны ачыклау, кисәтү һәм туктату ТР ЭТРМ вәкаләтенә карамаса, ТР ЭТРМ мондый бозулар турындагы мәгълүматны (белешмәләрне) Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының тиешле вәкаләтле дәүләт хакимияте органнарына (Татарстан Республикасы буенча табигатьтән файдалану идарәсе, ТР буенча Росприроднадзор идарәсе, Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең Идел буе идарәсе (Ростехнадзор), Татарстан Республикасы буенча Россельхознадзор идарәсе, Федераль су ресурслары агентлыгының Түбән Идел бассейны су идарәсенең ТР буенча су ресурслары бүлеге, Татарстан Республикасы буенча кулланучыларның хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт идарәсе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе, Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Прокуратурасы, “Гидрометеорология һәм Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен мониторинглау буенча идарә” федераль дәүләт бюджет учреждениесе) җибәрергә тиеш”.;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

“Юридик затның җитәкчесе, башка вазифаи заты яки вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле булмаганда, шулай ук тикшерелә торган зат тикшерү акты белән танышып чыгуы турында язунамә бирүдән баш тартканда яки танышудан баш тартканда, акт кулга тапшыру турында белдерүнамә белән, заказлы хат итеп почта аша җибәрелә һәм ТР ЭТРМ эшендә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә. Тикшерелә торган зат дәүләт контрольлеге (күзәтчелеге) яки муниципаль контрольлек кысаларында электрон рәвештә хезмәттәшлек итүгә риза булганда, тикшерү акты шушы актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән таныкланган электрон документ рәвешендә юридик затның җитәкчесенә, башка вазифаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә җибәрелергә мөмкин. Шул ук вакытта шушы актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән таныкланган электрон документ рәвешендә тикшерелә торган затка күрсәтелгән документның алынуын раслый торган ысул белән җибәрелгән акт тикшерелүче зат тарафыннан алынган булып санала”.;

5.2.2 пунктында “боерыгы (әмернамәсе)” сүзләрен “министр (министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе)” сүзләренә алмаштырырга;

5.2.3 пунктындагы өченче абзацта “министр (министр урынбасары) әмернамәсе” сүзләрен “министр (министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе)” сүзләренә алмаштырырга;

5.2.4 пунктында:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

“Тикшерү актын төзү өчен үткәрелгән тикшерүләрнең, сынауларның, махсус тикшерүләрнең нәтиҗәләре буенча бәяләмә алу кирәк булса, тикшерү акты контрольлек буенча чаралар тәмамланганнан соң өч эш көненнән артмаган вакытта төзелә һәм юридик затның җитәкчесенә, башка төрле вазифаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә имзалатып тапшырыла яисә кулга тапшыру турында белдерүнамә белән, заказлы хат итеп һәм (яки) шушы актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән таныкланган электрон документ рәвешендә (тикшерелә торган зат дәүләт контрольлеге (күзәтчелеге) яки муниципаль контрольлек кысаларында электрон рәвештә хезмәттәшлек итүгә риза булганда), күрсәтелгән документны алганлыкны раслый торган ысул белән җибәрелә. Шул ук вакытта кулга тапшыру турында белдерүнамә һәм (яки) күрсәтелгән документны алганлыкны алу турында раслый торган башка төрле дәлил ТР ЭТРМ эшендә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә”.;

җиденче абзацта “тикшерүләрне исәпкә алу дәфтәрендә” сүзләреннән соң “(булган очракта)” сүзләрен өстәргә;

5.3.1 пунктының дүртенче абзацында “әмернамәсе” сүзен “министр (министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе)” сүзләренә алмаштырырга;

5.3.5 пунктының өченче абзацын төшереп калдырырга;

5.4.3 пунктында:

беренче абзацта “боерыгы (әмернамәсе)” сүзләрен “министр (министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе)” сүзләренә алмаштырырга;

5.4.4 пунктында:

өченче абзацта “электрон санлы имзасы белән” сүзләрен “көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән” сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта “әмернамәсе” сүзен “министр (министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе)” сүзләренә алмаштырырга;

5.4.6 пунктындагы өченче абзацны төшереп калдырырга;

6.5 пунктының икенче абзацында “министр (министр урынбасары) әмернамәсе” сүзләрен “министр (министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе)” сүзләренә алмаштырырга;

7.4 пунктында:

беренче абзацта “Шикаятькә җавап бирелми” сүзләреннән соң “яисә шикаятьтә күтәрелгән мәсьәләнең асылы буенча җавап бирелми” сүзләрен өстәргә;

икенче абзацта “шикаятьне җибәрүченең, почта адресы” сүзләрен “шикаятьне җибәрүченең, яки почта адресы” сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

“- әгәр мөрәҗәгать итүченең шикаятендә элегрәк җибәрелгән шикаятьнең асылы буенча язмача җаваплар берничә тапкыр бирелгән булса һәм шул ук вакытта шикаятьтә яңа дәлилләр яки шартлар китерелмәсә (күрсәтелгән шикаять һәм алдарак җибәрелгән шикаятьләр бер үк дәүләт органына, җирле үзидарә органына яки бер үк вазифаи затка җибәрелгән булу шарты белән) (шикаятьне җибәрүче мөрәҗәгать итүчегә язышуларны туктату карары турында хәбәр ителә)”;

7.5 пунктындагы “мәгълүмати-телекоммуникация” сүзләрен төшереп калдырырга;

7.6 пунктында “тиешле гарызнамәне язмача” сүзләреннән соң “яки электрон” сүзләрен өстәргә.

3. Хокукый тәэминат бүлегенә (В.А.Тронин) шушы боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынуын тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту өчен министр урынбасары Ф.Ф. Шакировны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр Ф.С. Габделганиев